## КАРАР

**“19” ноябрь 2021 ел № 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе тәэелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Кышкар авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру, 1 данә.
- Кышкар авылында Мостовая урамы 45 нче йорттан 55 нче йортка, асфальт-бетон катламлы юлдан 53 нче йортка кадәр юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау;
- Кышкар авылында Мира, Мостовая, Победа урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;
- Кышкар авылы зиратының бер өлешен коймалап алу өчен материаллар сатып алу;
- янгын гидрантларына комплект җиһазлары сатып алу (1 данә янгын җиңсәсе, көчеш башламы, янгын колонкасы, янгын стволы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 174 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 93 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 93 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыенынәтиҗәләре дөрес.

2. « Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Кышкар авылында яңгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру, 1 данә.
- Кышкар авылында Мостовая урамы 45 нче йорттан 55 нче йортка, асфальт-бетон катламлы юлдан 53 нче йортка кадәр юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау;
- Кышкар авылында Мира, Мостовая, Победа урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;
- Кышкар авылы зиратының бер өлешен коймалап алу өчен материаллар сатып алу;
- янгын гидрантларына комплект җиһазлары сатып алу (1 данә янгын җиңсәсе, кучеш башламы, янгын колонкасы, янгын стволы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Новая урамы, 125 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова